
*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл – 30**

**1. Рәсемгә игътибар ит. Ул кайсы татар халык әкиятенә ясалган? Әкиятнең исемен яз. Геройларын ата. (5 балл)**



**2. «Су анасы» әкиятенең авторы кем? Дөрес җавапны билгелә. (1 балл)**

а) Фәнис Яруллин

ә) Абдулла Алиш

б) Габдулла Тукай

в) Муса Җәлил

**3. Роберт Миңнуллин шигырен билгелә. (1 балл)**

а) «Фатыйма һәм сандугач»

ә) «Камырша»

б) «Әни, мин көчек күрдем»

в) «Китап һәм балалар»

4. **Шигырьнең исемен, авторын яз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән төп хис-тойгыны билгелә. (10 балл)**

Уянды да
Тамчы тамды,
Әй сөенде,
Әй шатланды:
– Җиргә язны
Мин китердем!
Мин китердем!

Карга килде,
Горур бик тә:
– Мин килдемме,
Карлар китә.
Җиргә язны мин китердем,
Мин җиткердем!

Гөрләвек тә җырын сузды,
Челтер-челтер
Алга узды:
– Җиргә язны
Мин китердем!
Мин җиткердем!

**5. Дәрҗия Аппакованың «Шыгырдавыклы башмаклар» хикәясенең эчтәлеген исеңә төшер. Бирелгән вакыйгаларны хикәядәгечә дөрес урнаштыр. (3 балл)**

а) Гөлшатның әтисе сугыштан кайта.

ә) Әтисе Гөлшатка Мәскәүдән сары башмаклар җибәрә.

б) Ләлә өендә елап утыра, дус кызлары аны юатмакчы була.

в) Гөлшат башмакларны дусты Ләләгә күрсәтә.

г) Гөлшат сары башмакларын Ләләгә бүләк итә.

**6. Чын дуслык авырлык килгәндә беленә, диләр. Бу дөресме? Бу турыда фикерләреңне яз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытма. (10 балл)**